КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 октябрь г.Казань № 848

Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разряд) сайлап алу үткәрү пункты эше нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән Россия Федерациясеннән читтә бурычларны үтәү өчен хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән граждан-нарның балаларына бер мәртәбә акчалата түләү турында

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән Россия Федерациясеннән читтә бурычларны үтәү өчен хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарның социаль яклану дәрәҗәсен күтәрү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разряд) сайлап алу үткәрү пункты эше нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән Россия Федерациясеннән читтә бурычларны үтәү өчен хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданның 18 яшькә җитмәгән һәр баласына 20 000,0 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә (алга таба – бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү).

2. Кararга теркәлгән Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разряд) сайлап алу үткәрү пункты эше нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән Россия Федерациясеннән читтә бурычларны үтәү өчен хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданның 18 яшькә җитмәгән һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү эшен оештырырга;

«Социаль өлкәдә ярдәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм әлеге мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматларда бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка социаль ярдәм чаралары һәм дәүләт социаль ярдәме чаралары билгеләнгәндә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучы гаиләләрнең керемнәре составында исәпкә алынмый;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү чыганагы –Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы;

бу карарның гамәле 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 22 октябрь , 848 нче карары белән расланды

Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разряд) сайлап алу үткәрү пункты эше нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән Россия Федерациясеннән читтә бурычларны үтәү өчен хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданның 18 яшькә җитмәгән һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разряд) сайлап алу үткәрү пункты эше нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән Россия Федерациясеннән читтә бурычларны үтәү өчен хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданның 18 яшькә җитмәгән һәр баласына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү механизмын билгели (алга таба - бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү, бала).

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү өчен баланың законлы вәкиле (алга таба – гариза бирүче) «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең яшәү урыны буенча бүлегенә (алга таба шул ук эзлеклелектә – Үзәк, Үзәк бүлеге) яисә, гариза бирүченең Татарстан Республикасы территориясендә яшәү (тору) урыны булмаган очракта, Үзәкнең Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә кайсы бүлегенә, түбәндәге документларны теркәп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан расланган форма буенча бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза тапшыра:

а) банкларда һәм башка Россия кредит оешмаларында гариза бирүчегә ачылган шәхси счет реквизитлары бирелгән документ күчермәсен;

б) бала тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен;

в) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язмача ризалык;

г) балага опека (попечительлек) билгеләү турында документ күчермәсен (опекун билгеләнгән очракта);

г) Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разряд) сайлап алу үткәрү пункты тарафынннна бирелгән баланың әти-әнисе Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән Россия Федерациясеннән читтә бурычларны үтәү өчен хәрби хезмәт узу турында контракт төзү фактын раслаучы белешмәне.

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү өчен мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче шәхесне таныклый торган документ күрсәтә.

Документларның күчермәләре, документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) тарафыннан яки нотариуста таныкланмаса, төп нөсхәләрен күрсәтеп, бер нөсхәдә тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Гариза һәм аңа кушылган документларның күчермәләре Үзәккә почта аша җибәрелергә мөмкин. Бу очракта документларның күчермәләре документның

оригиналын биргән орган (учреждение) тарафыннан яки нотариаль рәвештә расланган булырга тиеш, шәхесне раслаучы документ күчермәсеннән тыш.

3. Гаризаларны теркәү журналында гаризаны теркәү, әгәр гаризага бу Тәртипнең 2 пункты нигезендә документларның барлык күчермәләре теркәлсә, Үзәк бүлегенә гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

4. Үзәк бүлеге гаризаны һәм документларны аларның барлык кирәкле күчермәләре булу-булмавына һәм билгеләнгән таләпләргә (тиешле рәвештә рәсмиләштерү, документлар күчермәләрендә өстәмә язулар, сызылган сүзләр һәм аларда әйтеп үтелмәгән башка төзәтүләр булмау) туры килү-килмәвенә тикшерә.

Әгәр гариза һәм аңа кушылган документларның күчермәләре әлеге Тәртипнең 2 пункты таләпләренә туры килмәсә, Үзәкнең бүлеге хезмәткәре гаризаны кабул итүдән баш тартуны язмача рәсмиләштерә һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлата.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр турында хәбәр итү һәм гаризаны кушылган документларның күчермәләре белән кире кайтару гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә башкарыла.

Документларның расланган күчермәләре белән гариза почта аша алынган очракта, гаризаны кабул итүдән баш тарту турында язмача хәбәр итү һәм аңа кушылган документларның күчермәләре белән гаризаны кире кайтару Үзәкнең бүлегенә гариза килгән көннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

5. Үзәк бүлеге, документларның дөреслегенә һәм бирелгән белешмәнең дөреслегенә шик барлыкка килгән очракларда, бирелгән вәкаләтләр чикләрендә гариза бирүчеләр тарафыннан бирелгән белешмәне өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

6. Үзәк, Үзәк бүлекләре гражданнарның алынган шәхси мәгълүматларының конфиденциальлеген һәм саклануын тәэмин итә, аларны дөрес кулланмау өчен «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясына ярашлы җаваплы була.

7. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү йә аны билгеләүдән баш тарту турындагы карар Үзәк бүлеге тарафыннан гариза теркәлгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә.

8. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы;

тапшырылган документлардагы (документлар күчермәләрендәге) белешмәнең дөрес булмавы;

гариза бирүче тарафыннан тапшырылган һәм (яки) ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынган бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү өчен кирәкле документларда (белешмәләрдә) каршылыкларның яисә туры килмәүләрнең булуы;

гариза тапшырыла торган балага бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне башка законлы вәкилгә билгеләү фактын билгеләү.

9. Гариза бирүчеләрнеңбанкларда һәм Россиянең башка кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү суммасын күчерү Үзәк тарафыннан бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә башкарыла.

10. Үзәк ел саен, хисап елыннан соң килгән елның 15 гыйнварына кадәр, Татарстан Республикасы бюджетының бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнары турында хисапны Министрлыкка тапшыра.

11. Министрлык ел саен, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү гамәлгә ашырылган елдан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.